# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Актүбә ш.т.п. № 1 «26» октябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 26 октябрьдәге узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде сорау буенча:

«Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, шулай ук 2 теркем инвалидлар өчен 400 сум күләмендә билгеләп, узара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә коелар урнаштырып, су белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, урамнарга: Каенлы, Радужная, Шатлык):

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 270 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 184 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 184 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. Сорау буенча:

«Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә эгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, шулай ук 2 теркем инвалидлар өчен 400 сум күләмендә билгеләп, узара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә коелар урнаштырып, су белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, урамнарга: Каенлы, Радужная, Шатлык).» - карарны кабул итергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районының
«Актүбә шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.Л. Севостьянов